
Бөек Җиңүгә 65 ел!

Исәнмесез хөрмәтле Рафик Сәхәиев!

Сезнең абыем Сибагатов Хидият Сибагатовичның футлярда табылган язуы турындагы хатыгызны алдым. Бу хәбәрне миңа авыл советыннан җиткергәннәр иде. Хатыгызны укыгачта бик дулкынландым.

Сугышка чыгып киткән вакытлары күз алларымнан тагын бер кат үзды. Миңа ул вакытта 7-8 яшь иде. Шулай булсада барысын ап-ачык хәтерлим. Абыем бик оста гармунчы иде. Сугышка чыгып китер алдыннан гармунын уйнап, җырлады. Көн бик карлы-буранлы иде. Чыгып киткәндә җиргә карап: „Эш көндә бик ышанычлы түгел, кире кайтуларымда икеле булыр" - диеп чыгып китте. Шул китүдән бер хәбәрдә алмадык. Әнием үлгәнче берәр хәбәр булмасмы диеп көтте. Абыемның гаиләсе юк иде. Сезгә аның фотографиясен җибәрәм. Хидият абый 1922 елда туган. 1942 елда сугышка алынды.

Миңа шушы шатлыкда, кайгыледә хәбәрне җиткерүегез өчен, хатым аша бик зур рәхмәтләремне белдерәсем килә. Изге эшегездә Аллаһы Тәгалә җиңеллекләр бирсен. Исән-сау йөрегез. Шулай ук Тверь өлкәсенең Зубцов районы территориясендә „Эзлү" отрядына да зур рәхмәтемне белдерәм.

Сәламәтлегем какшау сәбәпле үзем барып йөри алмыйм. Абыемның авыр туфраклары җиңел булсын. Абыем рухына багышлап догалар кылам.


Үзем абыемның җирләү көненә бара алмасамда, аның сөякләрен җир куенына тапшыру ышанычлы кулларда.

Тагын бер кабат сезгә рәхмәтемне белдерәм, ихтирам белән Хидия апагыз.

От кого Фашовой Х. С.
Откуда 422724 Атнинский р-он дер. Кубань
Индекс места отправления

09 07 09 2 1 КАЗАНЬ 420032

Кому а/я 122 „Отечество"
Куда г. Казань
Индекс места назначения 420039



**СИБГАТОВ Хидият Сибгатович, 1922, д.Кубян, моб. Атнинским РВК, ст. с-т, 88 сд, погиб 10.08.1942, зах. : Тверская область, Зубцовский р-н, д.Кошелево.**



| №№ по пор. | Фамилия, имя и отчество | Военное звание | Должность и специальность | Партийность | Место и год рождения | Каким РВК и какой обл. призван | Когда и по какой причине выбыл | Где похоронен | Имя, отчество и фамилия, адрес жены или родителей |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 190 | Миронов Никита Никитов. | кр-ц | рядовой | 1923 | Рязанск обл. Пителинск р-н село Потапьево | Сасовский РВК Рязан. обл. | Убит 10.8.42 г. | д. Кащеево Зуб. р-н. | Рязанская обл. Пителинский р-н с. Потапьево мать Миронова Е. П. |
| 191 | Максимов Степан Степ. | Ст. серж. | к/расчета | 1922 г. | БССР Гомельск обл. г. Речица м. с. завод | Речицкий РВК Гомельской обл. | " " | " " | БССР Гомельская обл. г. Речица м. с. завод отец Максимов Ст. Ив. |
| 192 | Сибятов Хал. Сибят. | " | " | 1922 | Тат. АССР Аишинский р-н д. Кубяк | Аишинский РВК Тат. АССР | " " | " " | Тат АССР Аишинский р-н Кубяк отец Хашхнев Сибят Изра |
| 193 | Панютин Алекс. Антон. | " | пом к/взв. | 1923 | Курск. обл. Конышевск. Нелецк с/с | Конышевский РВК Тат. АССР | " " | " " | Курск обл. Конышевский р-н Нелецк с/с мать Панютина Агафья |
| 194 | Антипин Федор Михеевич | кр-ц | ряд. | 1923 | Челяб. обл. Миньярск р-н г. Оша Первомайск. с/с | Миньярский РВК Челяб. обл. | " " | " " | Челябинская обл. Миньярский р-н г. Оша Первомайская ул. отец Антипин Ф. |
| 195 | Сущетин Георг. Вас. | с/инстр. | с/инструк. | 1921 | Уральск обл. Свердл. окр. Сильвинский з-д | Ленинский РВК Челяб. г. Ташкент | Пропал без вести 10.8.42 г. | " " | Уральск обл. свердл. окр. Сильвинский з-д отец Сущетин Вас. Яков. |
| 196 | Гладков Конст. Андр. | кр-ц | ряд. | 1902 г. | Свердл. обл. Ачинск р-н г. Ачит | Ачитский РВК Свердл. обл. | " " | " — " | Свердл. обл. Ачитский р-н г. Ачит ж. Гладкова Екат. Павл. |
| 197 | Дубровин Федор Фадеев | " | " | 1923 | Челябинск обл. Юргамыш. р-н д. Калтос. | Юргамыш. РВК Челяб. обл. | " " | " — " | Челяб. обл. Юргамышск р-н Скоблин с/с д. Калтоган отец Дубровин Ф. А. |
| 198 | Молоков Егор Федоров. | " | " | 1898 | Челяб. обл. Мехонск р-н д. Сладкиы. | Мехонский РВК Челяб. обл. | " " | " — " | Челяб. обл. Мехонский р-н Писан с/с |
| 199 | Малыгин Валент. Никол. | Ст. серж. | к/расчета | 1922 | Кировск обл. Нагорск. р-н Николаевский с/с д. Лыжная | Сталинский РВК г. Киров | " " | — | Киров. обл. Нагорск. р-н Николаев с/с д. Лыжная отец Малыгин |
| 200 | Пичугин Васил. Иванов | кр-ц | рядов | 1924 | Калининск. Кимрск. р-н с. Бугунино | Кимрский РВК Калинин. обл. | " " | — | Калининск. обл. Кимр. р-н с. Бугунино отец Пичугин Иван |
| 201 | Лупкин Григор. Самуил | " | " | 1922 | Гомельская обл. Новобелица | Тереховский РВК Гомельск обл. | " " | " — " | Гомельская обл. Новобелица Ленинская ул. 98б Лупкина Дор. Гр. |
| 202 | Акиманкин Мих. Афан. | Ст. серж. | Ком/взв. | 1922 | Рязанский обл. Сасовский р-н с. Оночково | Сасовский РВК Ряз. обл. | " " | " " | Рязанск. обл. Сасовск. РВК с. Оночково мать Акиманкина А. Гр. |
| 203 | Сазыкин Николай Семенович | кр-ц | рядовой | 1914 | Тамбовская обл. г. Мичуринск | Мичуринский РВК Тамбов. обл. | " " | " — " | Тамбовская обл. г. Мичуринск Вокзальная 30 жена Сазыкина Ал. |
| 204 | Тарасенко Фед. Стратонович | " | " | 1897 | Черниговск обл. Прилуцкий р-н Хут. Глинчино | Прилуцкий РВК Черниговск обл. | " " | " — " | Черниговская обл. Прилуцкий р-н хут. Глинчино Линовиц с/с жена Тарасенко. |
| 205 | Абросимов Владим. Никол. | " | " | 1923 | Челябинск обл. г. Троицк | Троицкий РВК Челябинской обл. | " | — | Челябинская обл. г. Троицк Подсобное х-во мать Абросимова А. А. |
| 206 | Матросов Григорий Васильев. | мл. серж. | к/отд | 1912 | Смоленская обл. д. Сешко | Гагаринский РВК | тоже | | Смоленская обл. Гжатский РВК д. Сашко мать Матросова Вера Ефимов. |
| 207 | Нестеренко Иван Петрович | кр-ц | ряд. | 1923 | г. Таганрог ж. д. п. | Астраевский РВК Ростовск обл. | Убит 6.8.42 г. | Зуб. р. Калин. обл. | г. Таганрог ж. д. ул. Ивона мать Нестеренко Варвара Федоровна |
| 208 | Скрыпкин Петр Трифонович | " | " | 1923 | Винницкая обл. Гасинский р-н с. Степашки | Каменский РВК Ростовской обл. | " 5.8.42 г. | д. Костино Зубцовский р-н Калининск обл. | Винницкая обл. Гайсинский р-н село Степашки Отец Скрыпкин Трифон Тим. |
| 209 | Калмуратов Корсибай | сержант | к/взвода | 1907 | Южно-Казахстанск обл. г. Чимкент Каратасский с/с | Володженский РВК Ростовской обл. | " " | Убит 5.8.42 г. | Южно-Казахстан обл. г. Чимкент Каратайский р-н Карший с/с Калинина жена Калмуратова Акан |


Начальник штаба дивизии

Военный комиссар

Начальник 4-го отделения


ЦТ НКО. 2592—42


Останки Сибагатова Хидията нашли бойцы отряда "Русь" из г. Старица Тверской области, командир Фрыгин Валерий Юрьевич. Найден в Зубцовском р-не Тверской области в мае 2009 года.
Похоронен 23.8.2009 в д. Веригино Зубцовского р-на Тверской области.




О поиске родственников к нам обратился Терентьев Александр Михайлович, Фонд по поиску и увековечению памяти жертв Второй мировой войны "Жить и помнить". г. Тверь.

Из блиндажа подняты останки 26 советских солдат. Только у двоих удалось прочитать записки в смертных медальонах, один из них уроженец Татарстана:





Тверской Фонд по поиску и увековечению памяти жертв Второй мировой войны «Жить и помнить» в мае 2009 года обратился в совместный Информационно-поисковый центр Общественной молодежной организации «Объединение «Отечество» РТ и Института информатики Академии наук РТ. С помощью работников Кубянского смс в июне нашли сестру солдата - Фаизову Хиндию Сибгатовну 1936 г.р.

СИБГАТОВ Хидият Сибгатович похоронен 23 августа 2009 года в д. Веригино Зубцовского р-на Тверской области.



16 ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН — СЕЗ КАЙЛАРДА ЙӨРИСЕЗ ИКӘН

# 67 елдан соң әйләнеп кайткан фотосурәт

Тоташ бер ел да 20 көн дәвамында сугышлар барган биредә. Тверь өлкәсенең Мәскәү тавында булган канкойгыч вакыйгалар турында белгәч, кемнең генә йөрәге телгәләнмәс. Эзләү отрядлары бүген дә көн саен яңадан-яңа солдат җәсәдләрен табып торалар. 65 елга якын билгесез булып яшәгән солдатларның исемнәре ачыклана. Күптән түгел алар Зубцов районының Гредякино авылы янында элеккеге немец блиндажына тап булалар. Аннан исә 26 солдат табыла, шуларның нибары икесенең генә медальоннары аша исемнәрен ачыклау мөмкин була. Арадан берсенең Әтнә районы Күәм авылы егете Һидият Сибгатов икәнлеге аермачык күренеп тора. Телгәләнеп беткән кәгазьдә солдатның үз кулы белән язганнарын укып карарга мөмкин. Егерме яшьлек укытучы егет 1942 елның 13 мартында сугышка алына. Өйгә аның бер хаты гына килеп кала. Рәсми документларда ул 1943 елның ноябрь аенда югалган, икенче бер архив язмасында 1942 елның 10 августында ук Зубцов районының Кошелево авылында һәлак булган дигән мәгълүматлар бар. Һидият Сибгатовның үлеменә бәйле өченче санны да теркәп куярга мәҗбүрбез: 2009 елның 23 августында ул кабат Тверь өлкәсе Зубцов районы Веригино авылында туганнар каберлегенә күмелә.

Бүген Күәм авылында Һидият абыйның бертуган сеңлесе Һиндия апа гомер кичерә. "Моңарчы бер хәбәр дә булмады. Исәндер кебек тоелды. Үлгәнлеге турында хәбәр ишеткәч, җирләп кайтканнан да авыр булды. Ул сугышка китәр алдыннан бик көчле буран башланды. "Көннәр дә өметсез, мин кайта алмам инде, – дип чыгып китте абый. Без бик күп идек, хәзер исә икәү генә исән", – дип сөйли Һиндия апа. Абыйсы турындагы беренче хәбәрне ул быел июнь аенда ишетә. Һәм шунда ук һушсыз егыла.

Болай да йөрәге авыртып торган Һиндия апаны редакциянең эзләү төркеме кабат борчырга мәҗбүр булды. Без аңа абыйсының фотосын алып кайтып тапшырдык. Аны редакциягә быел 667 солдатны җирләп кайтуда катнашкан Габделхак, Рәйсә, Мөнирә, Рәзифә Корбановлар алып килеп тапшырганнар иде. Габделхак абый исә Һиндия апага сеңелләренең озак еллар буе Зубцов районында урнашкан туганнар каберлекләренә барып йөрүләрен сөйләде. Быел исә ничек 80 табут белән күмү мәрасимен оештырылуын, әле сугыш барган җирләрдә һаман да солдатлар табылуын үз күзләре белән күрүен бәян итте. Кайбер табутлар өстенә фотосурәтләр дә тезгәннәр, аларны туганнары, якыннары, якташлары алып китәргә тиеш булалар. Шунда Корбановлар, Татарстан кешесе барлыгын күреп, җитәкчелеккә хәбәр итә. Һәм үзләре белән рәсемне алып кайтырга уйлыйлар.

Әнә шундый урау юллар белән алып кайткан фоторәсемдәге туганын Һиндия апа кулына ала-ала сөйде. "Зурайтканнар. Фотосы үзен эзләп табып, аның янында булып, кире безгә кайтты", – дип сөйли башлаган Һиндия апага карап аптырап калдык. Баксаң, июнь аенда Казанда эшләүче "Отечество" берләшмәсе хезмәткәре Рафик Сәләхиев Һиндия апага хат язып, абыйсының табылуы турында аңлатып, фотосын соратып, аны электрон почта аша "Мәскәү тавы" мемориаль берләшмәсенә җибәргән булганнар икән. Табут өстендәге фото әнә шул.

– Истәлегә булыр, моны сандык төбендә саргайган рәсем белән чагыштырып булмый. Бүген генә төшемә яшел киемдәге солдат кергән иде, ул миңа: "Син бер дә авырма, яме", – диде. Сез кайтасы булганга кергән икән", – дип сөйли Һиндия апа.

Туганын яисә баласын сугышның әнә шундый билгесез, хәбәрсез җирләре үз куенына сыйдырган кешегә мондый төшләр еш керәдер ул. "Әһлиуллам, Һидиятуллам", – дип соңгы көннәренә кадәр күрешергә өмет итеп яши 88 яшькә җитеп вафат булган әнкәләре Нәфисә апа да бала хәсрәтен җиңел генә кичерә алмаган. Тугыз бала арасында санаулы ир балаларының берсе дә озын гомерле булмый. Сөнгать фронтта 7-8 ел йөреп кайтканнан соң вафат була. Әһли кайта да яңадан китеп югала. Миңлеҗан исемлесе яшьтән суга батып үлә. Һидият исә өйдән чыгып китүенә бер ел тулганчы ук һәлак була. Һиндия апаның фотога карап: "Сез сугышта кырылмасагыз, безнең дә туганнарыбыз булыр иде", – дигәнендә никадәр хаклык барын аңлау өчен әнә шул югалтуларны кичерергә, шул хәтерне барларга кирәктер ул.

Рәсимә МУЛЛАЯНОВА

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

